**ГЛАВА МОЛЬКЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МӘЛКИ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**09.11.2023 ел.** **Мәлки авылы** **№ 3**

Гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль
районының Мәлки авыл җирлегенең
Кыр Буасы авылында гражданнар
җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлеге Уставының 22 ст. нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. 2023 елның 23 ноябрендә 13 сәгать 30 минутта Кыр Буасы авылы, Үзәк урамы, 51 нче йорт адресы буенча урнашкан Кыр Буасы авыл клубы бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлегенең Кыр Буасы авылында ***үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын*** билгеләргә.

2. 2023 елның 27 ноябрендә 11 сәгать 00 минутта Кыр Буасы авылы, Үзәк урамы, 2 нче йорт янында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлегенең Кыр Буасы авылында ***үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын*** билгеләргә.

3. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
"Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлегенең Кыр Буасы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче һәр балигъ булган һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:
*а) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:*
 - территорияне торак пунктның рөхсәтсез чүплекләреннән чистарту;
 - авыл җирлеге торак пункты территориясен тоту;
 - материаллар сатып алып су алу колонкалары өчен түбәләр төзү;
*-б) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:*

- материаллар сатып алып, суүткәргеч челтәрләрен ремонтлау;
*в) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту;*
- материаллар сатып алып зиратны чистарту, төзекләндерү һәм ремонтлау.»

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Мәлки авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән әлеге карарны игълан итәргә http://pravo.tatarstan.ru,Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Мәлки авыл җирлеге башлыгы Ф.П.Поляков